КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 25 сентябрь г.Казань № 866

2021 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2021 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләмнәрен;

2021 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләре башкаруга норматив чыгымнарны.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2020 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2019 ел, 13 сентябрь, 833 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2019 ел, 13 сентябрь, 833 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 19 март, 203 нче.

3. Бу карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 25 сентябрь, 866 нчы
карары белән расланды

2021 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнары һәм күләмнәре

| Т/с | Хезмәт күрсәтүләр исеме | Норматив чыгымнар, бер берәмлеккә 1 елга сум | 1 елга хезмәт күрсәтүләр күләме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Архив белешмә кәгазьләрен, архив күчермәләрен, архив өземтәләрен, гражданнарның законлы хокукларын һәм ирекләрен тормышка ашыру һәм дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен үтәүгә бәйле мәгълүмат хатларын бирү | 1 303,9 | 20 740 | үтәлгән соратып алулар саны, берәмлек |
| 2. | Архив документларыннан (күчермәләреннән) һәм аларның белешмә алу өчен эзләү чараларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү | 1 089,26 | 8 052 | уку залына керүләр саны, берәмлек |

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 25 сентябрь, 866 нчы
карары белән расланды

2021 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы»
Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан
дәүләт эшләре башкаруга норматив чыгымнар

| Т/с | Эш исеме | Норматив чыгымнар, бер елга сум |
|---|---|---|
| 1. | Архивларны архив документлары белән комплектлау | 14 617 836 |
| 2. | Архив документларының сакланышын тәэмин итү һәм аларны исәпкә алу | 29 966 563 |
| 3. | Архив документларының тасвирламасын эшләү, аларның белешмә алу өчен эзләү чараларын булдыру, архив фондларының составы һәм эчтәлеге турында белешмә характерындагы мәгълүмат бирү басмаларын әзерләү | 7 308 918 |
| 4. | Архив документларындагы дәүләт серен, закон тарафыннан саклана торган башка серләрне тәшкил итә торган мәгълүматларны саклау һәм аларның сер булуын билгеләнгән тәртиптә бетерүне оештыру | 2 923 567 |
| 5. | Архив эшчәнлеге һәм идарәнең документлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча консультация ярдәме һәм методик ярдәм күрсәтү | 4 385 351 |
| 6. | Архив документларының белешмә алу өчен эзләү чараларыннан «еректан торып» файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү | 5 116 242 |
| 7. | Архив документлары нигезендә мәгълүмат чараларын, бастырып чыгару һәм күргәзмә проектларын тормышка ашыру | 8 039 810 |

_______________________